ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Актаныш муниципаль районы Советының 2014 елның 20 ноябрендәге «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Актаныш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1 Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Җир салымы турында” 2014 елның 20 ноябрендәге 20 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктының 3.2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.1. Җирле үзидарә органнары, дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, корылмалар, парклар, скверлар, мәйданнар, гражданнар күмү урыннары (зиратлар), монументлар һәм һәйкәлләр астында булган җир кишәрлекләренә карата казна учреждениеләре, шулай ук биометрик чокырлар һәм себер түләмәсе, үләт базлары урнашкан җир кишәрлекләренә карата алар карамагындагы учреждениеләр»;

12. 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.23 пунктча өстәргә:

«3.23. Әлеге карарның 3 пунктында каралган ташламалар эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата гына бирелә дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Актаныш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш авыл җирлеге Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Бариев